**СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423181, РТ Новошешминский район с. Ленино, ул. 40 лет Победы д. 32

423181 РТ Яңа Чишмә районы ,Ленино авылы, Җиңүнең 40еллыгы урамы, 32

тел.: (8-4348) 3-44-16, факс: (8-4348) 3-44-10; Lenin.nsm@tatar.ru

Татарстан.Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге Советы
Карары

от 9 ноябрь 2019 нчы ел № 65-130

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының 2019 елның 9 октябрендәге 64-127 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә өстәмә кертү хакында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Ленино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлеге советын

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының 9.10.2019 ел, № 64-127 карары белән расланган Нигезләмәсенең 3.20 пунктчасын түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга: «Граждан җитди сәбәпләр (сәламәтлеге, инвалидлыгы һ. б. буенча) буенча гражданнар җыенында катнаша алмаса, аның шәхси гаризасы нигезендә, гражданинның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, яшәү урыны адресы, аның гражданнар җыенында катнаша алмавының сәбәбе, шулай ук аның гражданнар җыенына чыгарыла торган үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсенә турыдан-туры мөнәсәбәте булганда, граждан тавышы гражданнар Җыенының йомгаклау хисабында исәпкә алына».

2. Әлеге Карарны Интернет «мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru,

Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге башлыгы В.М. Веретенников

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "ЛЕНИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Р 06-585/14
СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ